**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3972**
**02.08.2019**

Башкарма комитетның «2016-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасын раслау турында» 2015 елның 29 декабрендәге 7510 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 нчы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2016-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасын раслау турында» 2015 елның 29 декабрендәге 7510 нчы карарына (Башкарма комитетның 2017 елның 28 мартындагы 1659 нчы, 2017 елның 6 июлендәге 4046 нчы, 2018 елның 29 мартындагы 1694 нче, 2018 елның 28 апрелендәге 2392 нче, 2018 елның 17 декабрендәге 7557 нче, 2019 елның 29 мартындагы 1606 нчы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программаны финанслауны Яр Чаллы шәһәре бюджетының «Гомумдәүләткә караган башка мәсьәләләр» 01.13, «Милли иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге өлкәсендәге башка мәсьәләләр» 03.14 бүлекләрендә (бүлекчәләрендә) каралган акчалар хисабына 2016 елда – 19884,35 мең сум, 2017 елда – 63807,85 мең сум, 2018 елда – 75181,55 мең сум, 2019 елда – 71749,27 мең сум, 2020 елда – 65595,48 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) «2016-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасында:

- паспортның 7 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары, мең сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | 19884,35 | 63807,85 | 69366,95 | 71749,27 | 65595,48 | 290403,9 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | 5814,6 | - | - | 5814,6 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 19884,35 | 63807,85 | 75181,55 | 71749,27 | 65595,48 | 296218,5 |
| | Искәрмә: Финанслау күләме прогноз характерына ия һәм тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. | | | | | | |

- программа чаралары системасын, шул исәптән еллар, чыганаклар буенча бүлеп, чаралар исемлеге һәм финанслау юнәлешләре булган программаны ресурслар белән тәэмин итүне яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Программа чаралары системасы, шул исәптән еллар, чыганаклар буенча бүлеп, чаралар исемлеге һәм финанслау юнәлешләре булган программаны ресурслар белән тәэмин итү

«2016-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм хокук бозуларны профилактикалау» шәһәр максатчан программасының программа чаралары системасы программага кушымтада күрсәтелгән.

2016-2020 елларга программаны финанслау күләме 296218,5 мең сум тәшкил итә.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет акчалары:

Чор өчен барлыгы 296218,5 мең сум, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча:

2016 елга – 19884,35 мең сум, 2017 елга – 63807,85 мең сум, 2018 – 75181,55 мең сум, 2019 – 71749,27 мең сум, 2020 – 65595,48 мең сум.»;

- 5.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикатор лары, үлчәү берәмлек ләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | | Финанслау (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2014 (база) | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| Максат: Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау буенча эшчәнлекне камилләштерү | | | | | | | | | | | | | | |
| 5. Урамнарда хокук тәртибен тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.12. «Куркынычсыз шәһәр» АПК өчен элемтә каналлары хезмәте күрсәтү | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | 2017-2020 | Шәһәр урамнарында кылынган җинаятьләр, берәмлек | 2500 | 2300 | 2100 | 1900 | 1700 | 1500 | - | 1144,43 | 3479,65 | 6181,2 | 0 |
| барлыгы: | | | | | | | | | | 19884,35 | 63807,85 | 75181,55 | 71749,27 | 65595,48 |

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев